# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 12.11.2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге составына керүче Сәпәй авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә, "2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча граҗданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә киметергә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Сәпәй авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукөиясе сатып алу, "Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Яңа ел" бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);
- Сәпәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Сәпәй авылында җәй көне территорияне чабу;
- Сәпәй авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясату һәм урнаштыру турындагы карары кабул ителде.

"РИЗА" "КАРШЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 490 кеше кергән, халык җыенында катнашучылар саны 294 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 294 кеше тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Сәпәй авыл җирлегенең Сәпәй авылында узган халык җыенын үтте дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре- дөрес.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Сәпәй авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);

- Сәпәй авылында юлларны кардан чистарту;

- Сәпәй авылында җәй көне территорияне чабу;

- Сәпәй авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясату һәм урнаштыру.

5. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Сәпәй авылы, Мәктәп ур. 53В йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Галиева